ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2026 Мөслим № 14

**Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны баланслы тукландыру нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 273-ФЗ Федераль законның 37 маддәсен үтәү йөзеннән, Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 213н номерлы боерыгы, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 11 мартындагы 178 номерлы боерыгы нигезендә, «Мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү учреждениеләрендә укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне тукландыруны оештыру буенча методик тәкъдимнәрен раслау турында» «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча һәм 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге 777 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025елның 21 апрелендәге 253 номерлы, «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алучыларны туклану белән тәэмин итү бәясенең нормативларын раслау турында» 2025 елның 03 октябрендәге 787 номерлы карары белән, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.1. Гомуми белем бирү оешмаларының урта, төп һәм башлангыч белем бирү оешмалары җитәкчеләренә
«Күбәк урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Михайловка урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Мөслим гимназиясе» МБГББУ
«Г.Тукай исемендәге Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
Мөслим лицее МБГББУ
«Тат. Бүләр УГББМ» МБГББУ
«Әмәкәй төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Баек төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Олы Чакмак төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«М.Бүләр төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Түбән Табын төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Яңа Усы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Рус Шуган төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Салауз-Мухан төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Тат.Шуран төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Тойгелде төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ

«Мәлләтамак башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
«Метрәй башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ
бер тапкыр кайнар туклану (кайнар иртәнге аш) оештырырга.

2. Барлык муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында 1-4 сыйныф укучыларын көненә 74,77 сум (җитмеш дүрт сум 77 тиен) күләмендә бушлай кайнар иртәнге аш белән тәэмин итәргә.

3. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы буенча, ГПД (озайтылган көн төркемнәрендә) шөгыльләнүче һәм күрше авыллардан төп мәктәпләрдә укучы укучыларга 25,00 сум (егерме биш сум 00 тиен) күләмендә өстәмә туклану оештырырга.

4. Урта һәм төп гомуми белем бирү оешмаларында 5-11 сыйныф укучылары өчен бер укучыга көненә кайнар иртәнге ашның бәясен 74,77 сум (җитмеш дүрт сум 77 тиен) күләмендә билгеләргә, шулардан 10,70 сум (ун сум 70 тиен) субсидия;

4.1. Белем бирү оешмасында туклануны оештыру процессына һәм түләүгә бәйле операцияләрне исәпкә алу өчен автоматлаштырылган исәпкә алу системасын куллану AVSU.RU (Система AVSU.RU) - ЭВМ һәм мәгълүматлар базасы өчен үзәк программасы.

5. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Хәбибуллина Л. Я.га:

5.1. Укучыларны кайнар тукландыруны оештыруга бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә.

5.2. Витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләр күләме буенча балансланган өстәмә туклану һәм кайнар иртәнге аш нормаларының һәм сыйфатының үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

5.3. Гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез керүен координацияләүне һәм тикшереп торуны тәэмин итәргә.

6. Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

6.1. Мәктәп ашханәләрен азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

6.2. Санитария нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклануга производство контроле уздырырга.

6.3. Ике тапкыр туклану мөмкин булмаганда югарыда күрсәтелгән туклану бәясе нигезендә акчалата компенсация бирүне оештырырга.

7. 5-11 сыйныф укучыларының түбәндәге категорияләрен кайнар иртәнге ашлары өчен түләүдән азат итәргә:

- дүрт һәм аннан да күбрәк балалы күп балалы гаиләләрдән укучылар;
- әти-әниләре полиция хезмәткәрләре булган укучыларны;
- әти-әниләре 1, 2 төркем инвалид булган укучыларны.

7.1. Түбәндәге укучыларны туклану өчен түләүдән азат итәргә:

- инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар.

8. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының төп һәм башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында 1-9 сыйныф укучыларын урта гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучыларын, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләреннән, РФ Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, РФ Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, ТРда оешкан «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән РФ Федераль куркынычсызлык хезмәтенең ТР буенча идарәсе, шулай ук гражданинның хәрби хезмәт үтү чорына махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категория гражданнарның гаиләләреннән (гаилә әгъзалары) укучыларны түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итәргә.

Әлеге карарда билгеләнгән ярдәм чаралары Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләре гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) кагыла, алар Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсонск өлкәсе тикшерү идарәләренә вазыйфаларына күчерү тәртибендә билгеләнгән».

8.1. Күрсәтелгән ташламаны хәрби комиссариатның гомуми белем бирү оешмасында укучының ата-анасын (законлы вәкилен) чакыру турындагы белешмәсе нигезендә бирергә.

9. Мөслим муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУна (Н.А.Бубековага) гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку вакытында туклануны оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

10. ТР Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның «31» декабреннән «Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2025 елның 22 гыйнварыннан, 17 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

11. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм ТР Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга https://pravo.tatarstan.ru/

12. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**